Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы

Зур Кукмара авыл җирлеге башлыгы

карары

2025 елның 30 октябре №99

«Кукмара муниципаль районы
Зур Кукмара авыл җирлегенең
Зур Кукмара авылы торак пунктында
гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2025 елның 14 ноябрендә 08 сәгать 30 минутка Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Зур Кукмара авылы, Мәктәп урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2025 елның 14 ноябрендә 09 сәгать 30 минутка Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Зур Кукмара авылы, Мәктәп урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. 2025 елның 14 ноябрендә 10 сәгать 30 минутка Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Зур Кукмара авылы, Мәктәп урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

4. 2025 елның 14 ноябрендә 13 сәгать 30 минутка Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Зур Кукмара авылы, Мәктәп урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

5. 2025 елның 14 ноябрендә 14 сәгать 30 минутка Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының бишенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Зур Кукмара авылы, Мәктәп урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

6. 2025 елның 14 ноябрендә 15 сәгать 30 минутка Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының алтынчы этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Зур Кукмара авылы, Мәктәп урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

7. Халык җыенын үткәрү өчен, яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

8. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләр кала, Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге Зур Кукмара торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2026 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

**тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;**

**урамнарны яктырту җайланмасы урнаштыру;**

**су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;**

**җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр);**

**яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;**

**беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;**

**һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) түгел) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү;**

**торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;**

**тротуарлар төзү, ремонтлау;**

**торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;**

**тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру;**

**торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өстендәге үтүләрне ремонтлау**

**каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү?**

**«РИЗА»** **«КАРШЫ»**

9. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Зур Кукмара авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

10. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Кукмара авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

11. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

ОГРН 1021607754981 ИНН 1623001678

Җирлек башлыгы Р. Р. Хәнәфиев